КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 27 апрель г.Казань № 533

Татарстан Республикасында хокукка сәләтле балигъ булган гражданнарга патронаж билгеләү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында

Сәламәтлегенә бәйле рәвештә үз хокукларын мөстәкыйль гамәлгә ашыра һәм яклый һәм үз бурычларын үти алмый торган хокукка сәләтле балигъ булган гражданнар хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасында хокукка сәләтле балигъ булган гражданнарга патронаж билгеләү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәне (алга таба – Нигезләмә) расларга.

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына Нигезләмәне куллану буенча аңлатмалар бирүне гамәлгә ашырырга.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 27 апрель, 533 нче
карары белән расланды

Татарстан Республикасында хокукка сәләтле балигъ булган гражданнарга патронаж билгеләү тәртибе һәм шартлары турында
нигезләмә

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә хокукка сәләтле балигъ булган гражданнарга патронаж билгеләү тәртибен билгели.

1.2. Әлеге Нигезләмәдә түбәндәге төшенчәләр кулланыла:

патронаж – сәламәтлегенә бәйле рәвештә үз хокукларын мөстәкыйль гамәлгә ашырырга һәм якларга һәм үз бурычларын үтәргә сәләтсез булган хокукка сәләтле балигъ булган гражданга ирекле рәвештә түләүсез ярдәм күрсәтү, ул әлеге граждан мәнфәгатьләрендә аның белән төзелә торган йөкләмә шартнамәсе, мөлкәт белән ышанычлы идарә итү шартнамәсе һәм башка шартнамә нигезендә гамәлләр кылу формасында башкарыла;

ярдәмче – сәламәтлегенә бәйле рәвештә үз хокукларын мөстәкыйль гамәлгә ашырырга һәм якларга һәм үз бурычларын үтәргә сәләтсез булган хокукка сәләтле балигъ булган гражданга патронаж гамәлгә ашыручы хокукка сәләтле балигъ булган граждан;

ярдәмче булуга кандидат – сәламәтлегенә бәйле рәвештә үз хокукларын мөстәкыйль гамәлгә ашырырга һәм якларга һәм үз бурычларын үтәргә сәләтсез булган хокукка сәләтле балигъ булган гражданның ярдәмчесе булырга теләк белдергән хокукка сәләтле балигъ булган граждан.

1.3. Патронаж ярдәмче билгеләү юлы белән билгеләнә.

1.4. Ярдәмче Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәгән, сәламәтлегенә бәйле рәвештә үз хокукларын мөстәкыйль гамәлгә ашырырга һәм якларга һәм үз бурычларын үтәргә сәләтсез булган хокукка сәләтле балигъ булган граждан тарафыннан билгеләнә.

1.5. Ярдәмче билгеләү вәкаләтләре Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы (алга таба – Министрлык) тарафыннан Министрлыкның муниципаль районнардагы (шәһәр округларындагы) социаль яклау идарәләре (бүлекләре) (алга таба – территориаль социаль яклау органнары) йөзендә гамәлгә ашырыла.

Территориаль социаль яклау органы тарафыннан әлеге вәкаләтләрне башкару йөзеннән ярдәмче билгеләүгә мохтаҗ гражданның яшәү шартларын тикшерүне уздыру өлешендә халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге катнаша.

1.6. Ярдәмче билгеләү турында мәсьәләне карау өчен Министрлык раслаган форма буенча ярдәмче билгеләүгә мохтаҗ граждан тарафыннан бирелгән ярдәмче

билгеләү турында гариза нигез була.

## II. Ярдәмче булуга кандидатларга карата таләпләр:

2.1. Ярдәмче булуга кандидатларга карата түбәндәге таләпләр куела:

Россия Федерациясе гражданлыгы булу;

яше балигъ булу;

ярдәмче билгеләүгә мохтаҗ граждан яши торган муниципаль районда, шәһәр округында яшәү урыны булу;

гражданны ярдәмче итеп билгеләп булмый торган түбәндәге авырулар булмау: хроник алкоголизм, наркомания, токсикомания, кискен йогышлы авырулар, вируслы гепатит (В, С), сифилис, кеше иммунодефициты вирусы (ВИЧ) китереп чыгарган авырулар, туберкулез, теләсә нинди формалардагы психик бозылышлар;

ярдәмче бурычларын үтәүне кыенлаштыра алган хезмәт эшчәнлеге факторлары һәм (яки) белем бирү оешмасында уку факторлары булмау (хезмәт командировкаларына еш җибәрелү һәм алар дәвамлы булу, башка торак пунктта озак уку);

алынмаган яки бетерелмәгән хөкемгә тартылган, шулай ук аеруча авыр җинаятьләр яки алдашу өчен алынган (бетерелгән) хөкем тартылган булмау.

2.2. Ярдәмче итеп түбәндәгеләр билгеләнә алмый:

ярдәмче билгеләүгә мохтаҗ гражданга социаль хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы оешма хезмәткәре;

хокукка сәләтсез һәм хокукка сәләте чикләнгән гражданнар;

ярдәмче вазыйфаларын башкарудан элек читләштерелгән ярдәмче эшчәнлеген контрольдә тотуны гамәлгә ашыру нәтиҗәләре буенча затлар;

## III. Ярдәмче булуга кандидатлар сайлап алу һәм аларны исәпкә алу

3.1. Территориаль социаль яклау органы ярдәмче булуга кандидатлар сайлап алуны һәм аларны исәпкә алуны гамәлгә ашыра.

3.2. Территориаль социаль яклау органы муниципаль район, шәһәр округы территориясендә яшәүче гражданнарга территориаль социаль яклау органы бинасында урнашкан мәгълүмат стендларында, массакүләм мәгълүмат чараларында мәгълүмат урнаштыру юлы белән ярдәмче булу мөмкинлеге турында хәбәр итә.

3.3. Ярдәмче булуга кандидат яшәү урыны буенча территориаль социаль яклау органына, түбәндәге документларны теркәп, ярдәмче итеп билгеләү турында гариза тапшыра:

1) шәхесне таныклый торган документ күчермәсе (чагыштырып карау һәм таныклау өчен төп нөсхәне күрсәтеп);

2) эш (хезмәт, уку) урыныннан эш (хезмәт, уку) характерының һәм эш шартларының кыскача тасвирламасы белән белешмә (хезмәт командировкаларына җибәрү ешлыгы һәм аларның дәвамлылыгы, башка торак пунктта озак уку, әгәр ярдәмче булуга кандидат эшләсә, хезмәт итсә яки укуса);

3) ярдәмче булуга кандидатның сәламәтлеге турында медицина бәяләмәсе;

4) Министрлык тарафыннан расланган форма буенча ярдәмче итеп билгеләү

(билгеләүдән баш тарту) турында карар (әгәр ярдәмче булуга кандидат ярдәмче билгеләүгә мохтаҗ конкрет граждан белән бергә мөрәҗәгать иткән булса);

5) Министрлык тарафыннан расланган форма буенча ярдәмче булуга кандидат буларак исәпкә кую (исәпкә куюдан баш тарту) турында карар.

3.4. Ярдәмче итеп билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар яки ярдәмче булуга кандидат буларак исәпкә кую турында (исәпкә куюдан баш тарту турында) карар хакында ярдәмче булуга кандидатка тиешле карар кабул ителгән көннән өч эш көне эчендә гаризада күрсәтелгән ысул белән (почта аша, электрон почта адресы буенча) хәбәр ителә.

Ярдәмче итеп билгеләүдән баш тарту турындагы карарда, ярдәмче булуга кандидат буларак исәпкә куюдан баш тарту турындагы карарда баш тарту өчен нигез күрсәтелә.

3.5. Ярдәмче итеп билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар яки ярдәмче булуга кандидат буларак исәпкә кую турында (исәпкә куюдан баш тарту турында) карар кабул ителгән көнне территориаль социаль яклау органы ярдәмче булуга кандидатларның гаризаларын һәм документларын исәпкә алу журналына тиешле язмалар язып куя.

3.6. Ярдәмче булуга кандидат буларак исәпкә кую турында карар кабул ителгән көннән ике ел эчендә гамәлдә була.

3.7. Ярдәмчегә булуга кандидат түбәндәге очракта исәптән алына:

аның гаризасы буенча;

ярдәмче итеп билгеләгәндә;

гражданны ярдәмче итеп билгеләүгә комачаулый торган түбәндәге вакыйгалар килеп чыгу турында территориаль социаль яклау органы белешмә алганда:

башка муниципаль районга, шәһәр округына даими яшәү урынына күченү;

ярдәмче бурычларын үтәүне кыенлаштыра алган хезмәт эшчәнлеге факторларын һәм (яки) белем бирү оешмасында уку факторларын ачыклау (хезмәт командировкаларына еш җибәрелү һәм алар озак дәвамлы булу, башка торак пунктта озак уку);

гражданның ярдәмче итеп билгеләп куела алмаган авырулар ачыклану;

алынмаган яки бетерелмәгән хөкемгә тартылган, шулай ук аеруча авыр җинаятьләр яки алдашу өчен алынган (бетерелгән) хөкемгә тартылган ачыклану;

гражданны хокукка сәләтсез һәм хокукка сәләте чикләнгән дип тану;

элегрәк гражданны ярдәмче бурычларын үтәүдән читләштерү турында мәгълүмат ачыклану;

ярдәмчегә булуга кандидат буларак исәпкә куелганнан соң ике ел вакыт узу.

3.8. Территориаль социаль яклау органы ярдәмче булуга кандидат Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән ярдәмче бурычлары һәм җаваплылыгы белән таныштырырга тиеш.

## IV. Ярдәмчене билгеләү тәртибе

4.1. Ярдәмче билгеләү турындагы мәсьәләне карау өчен ярдәмче билгеләүгә мохтаҗ граждан йә аның вәкиле территориаль социаль яклау органына шәхсән түбәндәге документлар белән ярдәмче билгеләү турында гариза тапшыра:

ярдәмче билгеләүгә мохтаҗ гражданның шәхесен таныклый торган документ

күчермәсе (чагыштыру һәм таныклау өчен төп нөсхәсен күрсәтеп);

гражданның үз хокукларын гамәлгә ашыруга һәм яклауга һәм үз бурычларын үтәүгә комачаулый торган чикләүләр булуын раслый торган сәламәтлеге турында медицина бәяләмәсе,

ярдәмче билгеләүгә мохтаҗ граждан вәкиленең шәхесен таныклый торган документ күчермәсе;

ярдәмче билгеләүгә мохтаҗ гражданның мәнфәгатьләрен тәкъдим итүгә ышанычнамә күчермәсе (әгәр гариза ярдәмче билгеләүгә мохтаҗ гражданның вәкиле тарафыннан бирелгән булса).

Документларның күчермәләре законнарда билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган очракта, алар документларның төп нөсхәләрен күрсәтеп тапшырыла һәм территориаль социаль яклау органы белгече тарафыннан таныклана.

4.2. Территориаль социаль яклау органы ярдәмче билгеләү турында гариза һәм аңа теркәлгән документлар кергән көнне аларны тикшерә һәм Министрлык тарафыннан расланган форма буенча алып барыла торган ярдәмче билгеләү турында гражданнар мөрәҗәгатьләрен исәпкә алу журналында терки.

4.3. Ярдәмче билгеләү турындагы гаризаны һәм документларны кабул итүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

әлеге Нигезләмәнең 4.1 пунктында каралган документларны тапшырмау;

срогы гамәлдән чыккан документларны тапшыру;

документларда билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган чистартылган, өстәп язылган урыннар, сызылган сүзләр һәм төзәтмәләр булу.

4.4. Документлар кергән (кабул ителгән) көннән өч эш көне эчендә территориаль социаль яклау органы ярдәмче билгеләүгә мохтаҗ граждан турындагы белешмәне аның яшәү шартларын тикшерү максаты белән ярдәмче билгеләүгә мохтаҗ гражданның яшәү урыны буенча халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге белгечләрен баруны оештыру өчен халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәгенә тапышыра.

4.5. Халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге территориаль социаль яклау органыннан ярдәмче билгеләүгә мохтаҗ граждан турында белешмә алган көннән биш эш көне эчендә:

гражданның яшәү урыны буенча баруны гамәлгә ашыра, аның яшәү шартларын тикшерә, аның нәтиҗәләре буенча Министрлык тарафыннан расланган форма буенча ярдәмче билгеләүгә мохтаҗ гражданның яшәү шартларын тикшерү актын (алга таба – тикшерү акты) төзи;

ярдәмче билгеләүгә мохтаҗ гражданнан ярдәмченең нинди ярдәме кирәклеге турында ачыклый;

территориаль социаль яклау органына тикшерү актын һәм гражданга ярдәмчесе ярдәме кирәк булган мәсьәләләр турында мәгълүмат җибәрә.

4.6. Территориаль социаль яклау органы халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәгеннән тикшерү акты һәм мәгълүмат алынган көннән 10 эш көне эчендә:

гражданның әлеге Нигезләмәнең 1.4 пунктында китерелгән шартларга туры килүен бәяли;

гражданн әлеге Нигезләмәнең 1.4 пунктында китерелгән шартларга туры килмәгән һәм (яисә) ярдәмче билгеләүгә мохтаҗ граждан тарафыннан бирелгән гаризада һәм документларда күрсәтелгән белешмә каршылыклы һәм (яисә) дөрес булмаган очракта, Министрлык тарафыннан расланган форма буенча ярдәмче билгеләүдән баш тарту турында карар кабул итә һәм аны (шәхсән мөрәҗәгать иткәндә) тапшыра яисә, баш тартуның сәбәбен күрсәтеп, гражданга почта аша җибәрә;

граждан әлеге Нигезләмәнең 1.4 пунктында китерелгән шартларга туры килгән очракта:

ярдәмче булуга кандидатны сайлап алуны гамәлгә ашыра;

граждан белән ярдәмче булуга кандидатның очрашуын оештыра;

ярдәмче билгеләүгә мохтаҗ гражданның һәм ярдәмче булуга кандидатның ризалыгы белән ярдәмче билгеләү турында карар рәсмиләштерә һәм, аларга кирәк булганда, ярдәмче һәм ярдәмче билгеләүгә мохтаҗ граждан арасында йөкләмә шартнамәсенең, мөлкәт белән ышанычлы идарә итү шартнамәсенең һәм башка шартнамәнең якынча формасын бирә;

әгәр ярдәмче билгеләүгә мохтаҗ граждан үзенә тәкъдим ителә торган кандидатны ярдәмче итеп килештермәгән булса, гражданга ярдәмче булуга башка кандидат сайлау эшен башкара.

4.7. Ярдәмче билгеләү турында карар кабул иткәндә:

территориаль социаль яклау органы мондый карар кабул ителгән көнне ярдәмче билгеләнгән гражданнарны исәпкә алу журналына ярдәмче билгеләнгән граждан турында белешмә язып куя;

ярдәмче билгеләнгән граждан һәм аның ярдәмчесе арасында ярдәмче билгеләү турында карар рәсмиләштерелгән көннән өч эш көне эчендә иң күбе ике ел срок белән йөкләмә шартнамәсе, мөлкәт белән ышанычлы идарә итү шартнамәсе һәм башка шартнамә төзелә.[1]

Шартнамә өч нөсхәдә – ярдәмче билгеләнгән граждан, ярдәмче һәм территориаль социаль яклау органы өчен берәр нөсхәдә төзелә.

4.8. Әгәр ярдәмче билгеләүгә мохтаҗ гражданга ярдәмчене билгеләү турында гариза кергән вакыттан алып бер ай дәвамында ярдәмче билгеләнмәгән булса, патронаж территориаль социаль яклау органы тарафыннан гамәлгә ашырыла. Территориаль социаль яклау органы әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән тәртиптә ярдәмчеләрне сайлап алуны дәвам итә.

## V. Ярдәмченең бурычлары

5.1. Ярдәмче билгеләнгән граждан белән төзелә торган йөкләмә шартнамәсе, мөлкәт белән ышанычлы идарә итү шартнамәсе яки башка шартнамә нигезендә ярдәмче аның мәнфәгатьләрендә гамәлләр кыла.

Шул ук вакытта ярдәмче билгеләнгән граждан тулысынча хокукка сәләтле

[1]Россия Федерациясе Граждан кодексының 1017 һәм 551 статьялары нигезендә мөлкәт белән ышанычлы идарә итү шартнамәсе дәүләт теркәвенә алынырга тиеш.

булып тора, теләсә нинди алыш-бирешләрне һәм башка юридик әһәмиятле гамәлләрне мөстәкыйль башкарырга хокуклы була.

Ярдәмче, шул исәптән ышанычнамә белән, ярдәмче билгеләнгән гражданныкы булган күчемле (күчемсез) мөлкәтне читләштерү буенча милек хокукында яисә файдалану хокукында алыш-биреш төзергә (башкарырга) хокуксыз булып тора.

5.2. Ярдәмче ел саен, хисап елыннан соң килә торган елның 1 апреленә кадәр, Министрлык тарафыннан расланган форма буенча үз өстенә алынган йөкләмәләрнең үтәлеше турында, шул исәптән граждан белән төзелгән йөкләмә, мөлкәт белән ышанычлы идарә итү шартнамәсе яисә башка шартнамә нигезендә ярдәмче билгеләнгән гражданның милкеннән файдалану турында язма рәвештә территориаль социаль яклау органына хисап кертергә тиеш.

## VI. Ярдәмче тарафыннан вазыйфаларны гамәлгә ашыру шартлары

6.1. Ярдәмче вазыйфаларын түләүсез башкара.

6.2. Үз бурычларын намус белән башкаручы ярдәмче үтенече буенча һәм ярдәмче билгеләнгән гражданның язмача ризалыгы булганда, территориаль социаль яклау органы ярдәмчегә, аның яшәү урыны ярдәмче билгеләнгән гражданның яшәү урыныннан ерак булган очракта, ярдәмче билгеләнгән гражданның мөлкәтеннән үз мәнфәгатьләрендә түләүсез файдаланырга рөхсәт итәргә хокуклы.

Бу очракта ярдәмче һәм ярдәмче билгеләнгән граждан арасында төзелә торган йөкләмә шартнамәсендә, мөлкәт белән ышанычлы идарә итү шартнамәсендә яисә башка шартнамәдә ярдәмче тарафыннан ярдәмче билгеләнгән гражданның түләүсез файдаланырга рөхсәт ителгән мөлкәт составы һәм ярдәмче тарафыннан аннан файдалану срогы күрсәтелергә тиеш.

## VII. Патронажны туктату

7.1. Әлеге Нигезләмә нигезендә билгеләнгән патронаж закон яисә шартнамәдә каралган нигезләр буенча йөкләмә шартнамәсен, мөлкәт белән ышанычлы идарә итү шартнамәсен яисә башка шартнамәне туктатуга бәйле рәвештә туктатыла.

Ярдәмче билгеләнгән граждан закон яисә шартнамәдә каралган нигезләр буенча йөкләмә шартнамәсе, мөлкәт белән ышанычлы идарә итү шартнамәсе яисә башка шартнамә туктатылган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә әлеге Нигезләмә буенча үзенә билгеләнгән патронаж туктатылу турында территориаль социаль яклау органына язмача хәбәр итәргә тиеш. Әлеге хәбәрнамә территориаль социаль яклау органына шәхсән тапшырылырга яисә почта аша яисә «Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасындагы шәхси кабинет аша электрон документ рәвешендә җибәрелергә мөмкин.

Территориаль социаль яклау органы хокукка сәләтле балигъ булган граждан ярдәмчесенең үз вазыйфаларын үтәвен контрольдә тотуны гамәлгә ашырырга һәм патронаждагы гражданга аның ярдәмчесе тарафыннан җибәрелгән һәм алар арасында төзелгән йөкләмә шартнамәсен, мөлкәт белән ышанычлы идарә итү шартнамәсен яисә

башка шартнамәне өзү өчен нигез булган бозулар турында хәбәр итәргә тиеш.

## VIII. Территориаль социаль яклау органы ярдәмченең үз вазыйфаларын үтәвен контрольдә тотуны гамәлгә ашыру тәртибе

8.1. Территориаль социаль яклау органнары ярдәмченең үз вазыйфаларын үтәвен контрольдә тотуны гамәлгә ашыра, бу максатларда план буенча һәм планнан тыш тикшерүләр үткәрә.

План буенча тикшерүләр территориаль социаль яклау органының эш планы нигезендә, әмма кимендә алты айга бер тапкыр башкарыла.

Планнан тыш тикшерүләр территориаль социаль яклау органы җитәкчесенең боерыгы нигезендә ярдәмченең үз бурычларын тиешенчә үтәмәвен дәлилли торган мәгълүмат буенча үткәрелә.

8.2. Территориаль социаль яклау органы ярдәмченең үз бурычларын үтәвен контрольдә тотуны гамәлгә ашыру максатларында ярдәмчедән ярдәмченең үз өстенә алган йөкләмәләрен үтәвен раслый торган документларны һәм мәгълүматларны бирүне таләп итәргә хокуклы.

8.3. Тикшерү үткәрү кысаларында ярдәмче билгеләнгән граждан һәм аның ярдәмчесе арасында төзелгән йөкләмә шартнамәсе, мөлкәт белән ышанычлы идарә итү шартнамәсе яисә башка шартнамә шартлары ярдәмче тарафыннан үтәлүгә бәйле барлык мәсьәләләр карап тикшерелә.

Тикшерү нәтиҗәләре буенча Министрлык тарафыннан расланган форма буенча ярдәмченең үз бурычларын үтәвен тикшерү акты төзелә.

8.4. Ярдәмче тарафыннан җибәрелгән һәм аның белән ярдәмче билгеләнгән граждан арасында төзелгән йөкләмә шартнамәсен, мөлкәт белән ышанычлы идарә итү шартнамәсен яисә башка шартнамәне өзү өчен нигез булган бозулар ачыкланган очракта, территориаль социаль яклау органы тикшерү тәмамланган көннән өч эш көне эчендә:

ярдәмче билгеләнгән гражданга аның ярдәмчесе тарафыннан җибәрелгән һәм алар арасында төзелгән йөкләмә шартнамәсен, мөлкәт белән ышанычлы идарә итү шартнамәсен яисә башка шартнамәне өзү өчен нигез булган бозулар турында хәбәр итә;

патронажны туктату турында карар кабул итә, таныкланган күчермәләрен ярдәмче билгеләнгән гражданга һәм аның ярдәмчесенә бирә.

## IX. Йомгаклау нигезләмәләре

9.1. Әлеге Нигезләмәне гамәлгә ашыру кысаларында кабул ителә торган территориаль социаль яклау органы карарларына карата Россия Федерациясе законнары нигезендә суд тәртибендә шикаять бирелергә мөмкин.

9.2. Территориаль социаль яклау органы әлеге Нигезләмәне гамәлгә ашыруга бәйле документларны алып баруны һәм саклауны тәэмин итә.

---